**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица Ключевая, дом 15, село Новое Ильмово, Черемшанский район, РТ, 423118

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЯҢА ЭЛМӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Чишмә урамы, 15 нче йорт, Яңа Элмәле авылы, Чирмешән районы, РТ, 423118

Телефон: (84396) 2-45-51, факс: (84396) 2-45-51 email: Nilm.Cmn2@tatar.ru

№152 27.12.2024 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының
Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 83 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 83 номерлы карарына (җирлек Советының 20.10.2020 ел №7, 17.11.2022 ел №71, 30.01.2023 ел №79,

20.06.2024 ел №128 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 3 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладлы күләме 13990 сум тәшкил итә»;

1.2. «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре» 2 нче кушымтасын яңа редакциядә 1 нче кушымтада каралганча бәян итәргә.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Элмәле авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе И.М. Җамалтдинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының
.2024 №  карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының
2018 елның 25 апрелендәге
№ 83 карарына 2 нче кушымта

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы
авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 19173 |